РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
“13” апрель 2023

КАРАР
№ 328

**Алты яшь тә алты айга җитмәгән балаларны һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга өйрәтү өчен муниципаль белем бирү оешмаларының беренче сыйныфына кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен яңа редакциядә раслау турында.**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 28 июлендәге 884 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы турындагы Нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.2.21 пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 02 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы (08.2021 N 707, 30.08.2022 N 784, 23.01.2023 N 47 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә карар бирәм:

1. Яңа редакциядә кушымта итеп бирелгән башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга муниципаль мәгариф оешмаларының беренче сыйныфына алты яшь тә алты айга җитмәгән балаларны һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүгә рөхсәтләр бирү тәртибен расларга.

2. Гамәлдән чыккан дип исәпләргә:

Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укытуга муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 1 классына алты яшь алты айга кадәр яшьтәге һәм сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында” 2020 елның 17 ноябрендәге 408 номерлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (http:pravo.tatarstan.ru.) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының (http://atnya.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты “Мәгариф бүлеге” МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов